Г.Р.Гайнуллина

Казан

**Илдар Әбүзәров хикәяләрендә нарратив дискурс ( «Корбан-роман» хикәясе мисалында)**

Заманында Р.Кутуй үзенең әдип буларак фаҗигасе хакында әрнеп Рабит Батуллага болай сөйли: “Вы же татары не читаете Кутуя, думая что он русский поэт. А русские не читают Кутуя, думая что он татарин. Татарлар мине урыс дип укымый, урыслар исә мине татарга саный. Менә, дустым, бу Кутуйның фаҗигасе! Казанда мин урыс, Мәскәүдә – татарин. Кайда да мин чит-ят кеше”

Бүгенге рус телле татар әдипләренең хәле башкарак, чөнки хәзерге татар прозасының үсеше турында сүз алып барган вакытта, әдәбиятның бу канатын читләтеп үтү мөмкин түгел.

Рус телендә иҗат итүче интеллекталь проза вәкиле Илдар Әбүзәров (1976) соңгы еллар прозасына әдәби образлар һәм детальләр белән төгәл һәм зәвыклы эш итүе белән танылып, кыю үтеп керә. Аның тәүге “Корбан-роман” (2009 елда бас.) дип исемләнгән китабына киң катлам укучы яратып өлгергән “Корбан-роман”, “Почта”, “Мавр” һ.б. хикәяләре кертелә.

Безнең максат – авторның “Корбан-роман” (бер корбан тарихы) хикәясендә хикәяләү үзенчәлеген – нарратив дискурсны ачу. “Хикәя – нарратив дискурсның иң ачык өске катламы. Коммуникация биредә нарратор һәм хикәяләүче тарафыннан тәкъдим ителгән персонаж-акторлар дискурсына нигезләнә. Ике дискурсның кушылмасы хикәя хасил итә, биредә вакыйга (диегезис) хикәяләнә” (2, 167).

И.Әбүзәровның “Корбан-роман” хикәясе “корбан” мифологик мотивын уйнату ярдәмендә авторның яшәеш хакындагы уйлануларын “чишү” кебек укыла. Текстның беренче өлеше “татар халкында бик күптәннән уздырылып килгән йола

бәйрәме – корбан китерү” (3, 155) вакыйгасын сөйләү икенче – корбанчыллык, хәтер мотивларын алга куеп сөйләнгән вакыйганы шәрехләргә ярдәм итә.

“Сирәк очрый торган талантлар” Стасик, Витек, Белосток филармониясенең солистлары Юныс (яки Юся), хикәяләүче һәм ноталар һәм грампластинкалар белән сату итүче эшкуар Венцеслав Бохоник янындагы фермага Корбан гаете алдыннан сыер алырга киләләр. Әдәби детальләрне җентекләп капма-каршы яисә янәшә куюда авторның яшәешне аңлауда һәркемнең үз дөреслеге, дигән фәлсәфәсе сиземләнә: *“А мы стояли и смотрели, как наша двухмесячная зарплата утекает сквозь <u>тонкие музыкальные пальцы</u> Стасика <u>в пухлые ладошки</u> пани директора. Но нам абсолютно <u>не было жаль денег</u>, совсем наоборот, мы <u>с презрением</u> смотрели, как пани директор их тщательно пересчитывает”(ассызыклау безнеке – Г.Г.) /”Ә без ике айлык хезмәт хакыбызның Стасикның нечкә музыкаль бармакларыннан пани директорның йомшак учларына агылуын карап басып тордык. Безгә ул акчалар тамчы да жәл түгел иде, хәтта киресенчә, без пани директорның аларны җентекләп кат-кат санавын җирәнеп диярлек карап тордык”* (*тәрҗемә Л.Әбударванык*ы) (1, 16). Корбан китерү ниятен Вецек белдерә, иптәшләренә тәкъдим итә.

Хикәяләү сыер сую вакыйгасын җентекләп тасвирлау белән дәвам итә. “Колаклары ак, аяклары ак, күзләре чем-кара” сыерны музыкантларга пан Тадеуш үзе сайлап бирә. Алдагы үлемнән котылырга ашкынган сыер сурәте дә текстның икенче өлешен “уку” өчен: *“И тогда я с трясущимися руками взял буренку за рога. Я поборол в себе страх и старался держать изо всех сил, но корова изо всех сил старалась не поддаться мне. Вот тут-то я увидел ее черные-черные бездонно грустные глаза, пока не опустила голову и не уперлась рогами в кормушка” /“Шунда мин калтыранган кулларым белән малкайның мөгезләреннән эләктереп алдым. Куркуымны җиңеп, бөтен көчемә тоттым, әмма сыер да бөтен көченә бирешмәскә тырыша иде. Менә шунда мин аның төпсез, сагыш тулы кара күзләрен күреп калдым. Аннан соң ул башын түбән иде дә мөгезләре*

*белән аранга терәлде”* (*тәрҗемә Л.Әбударованыкы*) (1,19) . Маруся кушаматлы корбан текстның икенче өлешендәге сөйгәнен савыктыру өчен эфтаназия – корбанга барган Марыся исемле кыз вакыйгасын укырга ярдәм итә.

Сыерны чалу вакыйгасының җентекле сурәте дә текстның соңында аңлана: *“Закрыв глаза, прислушиваясь только к протяжному пению ветра, я снял перчатки и положил руку на огромную, теплую шею коровы, другой рукой поднося к теплу ее жизни лед тесака” / “Күзләремне йомдым да бары тик җилнең озын көен тыңлый-тыңлый, перчаткаларымны салдым һәм бер кулымны сыерның киң, җылы муенына куйдым, икенче кулым белән аның гомеренең шушы җылысына пычак бозын китердем”* (*тәрҗемә Л.Әбударованыкы*) (1,22). Хикәянең икенче өлеше – Сират күпере образын һәркемнең йөрәк түрендә яшәүче гамь, уй, борчу дип төгәлләштерү аша автор аңлаган яшәеш фәлсәфәсен җиткерү урыны: *“В каждом из нас есть внутренний мост Сират; он же внутренний меч, позволяющий переходить из бытия в небытие. Он как дамоклов меч над пульсирующей шеей. Он ближе к нам, чем яремная вена. Он сечет и ранит в самое сердце” / “Безнең һәркайсыбызның күңелендә Сират күпере бар; ул, шулай ук, кылыч та – бу дөньядан теге дөньяга күчәргә ярдәм итә. Ул җылы кан ага торган муен тамырына куелган домоклав кылычы кебек. Ул безгә кан тамырыннан да якынрак. Ул йөрәккә кадала һәм яралый”.* (*тәрҗемә Л.Әбударованыкы*) (1,51). Вакыйгалар катламында Стася-Витуся-Марыся мәхәббәте өчпочмагы сөйләнелә. Автомобиль астында калган Стасяны коткару өчен аны яраткан кызларның тән әгъзаләре алыну, сөйгәнен коткару өчен корбан булган Марыся турында уйланулар әсәрнең фәлсәфи нигезен тотып тора. Хәтер мотивы корбан мотивы белән янәшә куела: *“Ну как вы думаете, что более жертвенно: умереть во имя любимой, зная, что она тут же забудет о вас и никогда не вспомнит. Не вспомнит даже вашего имени и лица, не говоря уже о вашем жертвенном поступке. Или принести себя в жертву, спасая человека, в которого по уши влюблена ваша ненаглядная. Иначе говоря, спасти собственного*

*соперника ценой собственного счастья. Или несчастья – кому как больше нравится". /"Ничек уйлыйсыз соң: кайсы корбан зуррак? Яраткан кешең хакына, аның синең турыда шунда ук онытачагын һәм беркайчан да искә төшермәячәген белә торып, гомереңне корбан итүме? Ул синең исемеңне дә, йөзеңне дә исенә төшермәячәк, аның хакына үлүең турында сөйләп тә торасы юк. Яки үзеңне син үлеп ярата торган кешенең яраткан кешесе өчен корбан итүме? Ягъни үз бәхетеңне корбан итеп көндәшеңне коткарыргамы? Ну, бәхетсезлегеңнеме инде – кемгә ничек ошый..."* (*тәрҗемә Л.Әбударованыкы*) (1,35-36). Текстның ахырында хәтер корбанга караганда мөһимрәк, дигән нәтиҗә ясала: *"А еще я верил, что в конечном итоге мы оказались счастливее Стасика, потому что ... он не помнил их жертвенной любви. А мы помнили". / "Тагын мин Стасиктан бәхетлерәк булуыбызга ышана идем, чөнки ... ул аларның нәрсә белән һәм нәрсә хакына корбан итүләрен хәтерләми. Ә без хәтерлибез".* (*тәрҗемә Л.Әбударованыкы*) (1,51). Автор тәкъдим иткән яшәеш фәлсәфәсе тулысынча укыла: кешене кеше итеп хәтер генә яшәтә, гамьсезлектән коткара ала, корбанчыллык, хәтер булмаганда, үзен акламый.

Әлеге фәлсәфәне "чишү", табу барышында нарраторга йөкләнгән тагын бер уен ачыла. Текст театр, музыка сәнгатенә караган чит текстлар белән баетылган. Хикәяләүче һәм персонажлар кичергән хисләр интертекстуаль шартлылык ярдәмендә көчәйтелә. Автор укучыны сәнгать дөньясына алып керә, аны кабул итү юлын күрсәтә.

Вакыйгалар барган икенче урын буларак Белостоктагы "Музыкальное кафе" сайлана. Яшәешне аңлауга Паганини каприслары ярдәм итә, хикәя структурасында бу деталь кабатлана. Сөйгәне хыянәтен кичерүдән авыруга сабышкан прима-балерина Марыся "Жизель" балетын модернизацияләргә кирәк, дип уйлый: текст Жизельның яраткан кыңгырауларын җыюдан башлансын, соңыннан шул кыңгырауларныны Альберт аның каберенә китерсен, дип үз язмышын укучыдан укыта. Марысяның сагышы Перселлның "When I am iaid in

earth”ы һәм Вердиның Pace, mio dio”сы белән чагыштырыла. Сыер чалу белән бәйле кичерешләр тасвиры – кызыл шәраб – кан кебек, агы сөткә охшаган булуы Беллининың “Mira o Norma”сы аша аңлатыла. Геройлар “Bella figlia dell amore”, “Donna non vidi mai”, “Небесная Аида” ария һәм дуэтларын тыңлап, лимонад кушылган җиңелчә сыра уртлый-уртлый бефстроганннар ашый-ашый, минерал су кушылган ак шәраб эчкәндә, “Мадам Баттерфляй”дан “Vogliatemi bene”, “Мадам Бовари”, “Мадам Клико”, “Гастон Шарпантье Шато Брюне Сент-Эскаль”ның мәхәббәт дуэтлары укучыга ишеттерелә кебек. Аллаһның рәхмәтенә өмет итү – Вердиның “Pace, mio dio” юллары, дип фикерләр башка сәнгать теленә күчерелеп, яшерелеп, уен төсендә тәкъдим ителә, Сәнгать текстлары белән таныш булмау “киң пландагы авторны” (3, төгәл аңлаудан ерагайта.

Шул рәвешле, И.Әбүзәров прозаның чит текст белән файдалану мөмкинлеге аша укучыны сәнгатькә тарта, әдәби табышмакларны чишү барышында нарратор һәм нарратор арасында коммуникация үзгә – интеллектуаль яссылыкка күчерелә.

Кулланылган әдәбият:

1. Абузяров И.А. Курбан-роман: рассказы. – М.: Центр книги ВГБИЛ им.М.И.Рудомино, 2009. 288с.

2. Ильин И.П. Постмодернизм. Словарь терминов. – М.: ИНИОН РАН (отдел литературоведения) – INTRADA. 2001. 384с.

3. Саморукова И.В. Художественное высказывание как эстетическая деятельность: типология и структура креативного опыта в системе дискурсов. Автореф.дисс. докт. филол.н.– Екатеинбург, 2004. 43 с.

4. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д–С). – Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.